**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада биремнәре (муниципаль тур, 2018-2019 уку елы) 7 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты- 120 минут**
**Максималь балл – 40 балл**

**I. Әдәбият теориясенә караган биремнәр (12 балл).**

1. Поэма жанрына хас үзенчәлекләрне Һ. Такташның “Мокамай” поэмасы мисалында аңлатыгыз (10 балл).
2. Поэма кем исеменнән сөйләнелә? Бер сүз яки сүзтезмә белән язып куегыз (2 балл).

**II. Әдәби иҗатка караган биремнәр (18 балл).**

1. Чистай районы Яуширмә авылы – Чистай – Оренбург – Берлин – Анкара – Истанбул. Әлеге урыннар кайсы әдип исеме белән бәйләнгән? (3 балл).
2. Бу әдип әдәбиятның кайсы төрләрендә иҗат итә? Бер җөмлә белән язып куегыз (3 балл).
3. Г.Исхакыйның “Җан Баевич” әсәрендә автор нинди сыйфатлардан көлә? Үз фикерегезне дәлилләп языгыз (6 балл).
4. Әлеге әсәрдә Шакирҗанга хас сыйфатларны капма-каршы ике төркемгә – уңай һәм тискәре сыйфатларга бүлеп языгыз (6 балл).

**III. Иҗади эш (10 балл).**

Түбәндәге сүзләрне танылган шагыйрьнең әсәреннән бер строфалык шигырь итеп формалаштырыгыз: *ыштансыз, белән, әкияттәге, үрмәләп, кебек, идек, бергәләп, каен, ике, танышып, бала, дөнья, башларына, ике, йөргән, малай.*